Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге Советы

**КАРАР №3**

Масловка авылы 06.02.2026

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советының 23.12.2025 елның №12 номерлы «2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге бюджеты турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив актны законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Масловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Балык Бистәсе муниципаль районының Масловка авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советының «Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына бюджеты турында» 23.12.2025 №12 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 10 өлешенең 2 пунктында» сүзләрен « Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясында»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Масловка авылы, Үзәк урамы, 13 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге башлыгы А.И.Егоров